# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пунктында гражданнарга үзара салым кертү турында

19 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 һәм 69 маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Яңа Мәлкән" авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пунктында халык җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Яңа Мәлкән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 һәм 2 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, МХОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларынан, МХОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш).
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар өчен мәйданчыкларны, бүленеш пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән җиһазларны ремонтлау - яктырткычлар сатып алу.

2) Яңа Мәлкән торак пункты чикләрендә Тапиков урамындагы гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Халык җыены нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы З. И. Нәҗметдинов

ОГРН 1021605552825
р-06-112/09
Совет
НОВОМЕЛЬКЕНСКОГО
сельского поселения
ИНН 1628002878